# ПРОЕКТТА КАТНАШЫРГА АШЫК!

**Республикада "Башкортстан лидерлары" конкурсының беренче этабы бара. Аны булдыру турындагы указга Башкортстан Башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров кул куйды. Документка ярашлы, проект гражданнарның идарә куәтен ачыклау, үстерү һәм аңа ярдәм итү, шулай ук, дәүләт власте һәм урындагы үзидарә органнарын, оешмаларны һәм предприятиеләрне кадрлар белән тәэмин итү сыйфатын күтәрү максатларында гамәлгә ашырыла.**

Моңа бәйле Башкортстан Башлыгы Хакимияте җитәкчесе Александр Сидякин брифинг үткәрде. Анда ул журналистларның сорауларына җавап бирде.

– "Башкортстан лидерлары" проекты нәкъ менә бүген кирәк, – диде Александр Сидякин. – Республикада берберсен тулыландыручы гамәлләр тормышка ашырыла. Без уңай мохит барлыкка килүен күрәбез. Кешеләр республика үсеше, идарә итү процессларында катнашырга тели. Һәм бу бездә оптимистик рух уята. Талантлы яшьләр әлеге проект белән файдаланырга тиеш.

# ТӨБӘК БРЕНДЫН АЛГА ЭТӘРҮ ПЛАНЫ РАСЛАНДЫ

**Республика Башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров агымдагы елда "Башкортстан продукты" төбәк брендын Русиядә һәм чит илләрдә таныту һәм алга этәрү планын раслады.**

Документ проект дипломантларының күргәзмә-ярминкә һәм конгресс чараларында катнашуы, аларның халыкара электрон сәүдә мәйданчыкларында үз товарларын һәм хезмәтләрен урнаштыруга кызыксындыру, тышкы икътисади эшчәнлек буенча укыту программаларында катнашу, экспорт товарлары каталогын булдыру һәм арытаба аны Русия сәүдә вәкиллекләре аша чит илләрдә тарату, шулай ук, чит ил аудиториясе өчен интернет-ресурслар челтәрен формалаштыру чаралары исемлеген билгели.

"Башкортстан продукты" проекты алтынчы ел гамәлгә ашырыла. Бу вакыт эчендә республиканың 416 предприятиесе дипломант булды. Бу марка белән 12 меңнән артык төр продукция билгеләнә. Әлеге вакытта республиканың 15 дипломант предприятиесе продукцияне экспортка озата.

"Башкортстан продукты" проектында катнашу продукцияне алга этәрүдә мәгълүмати һәм консультация ярдәмен тәэмин итә, төрле дәрәҗәдәге күргәзмәләрдә катнашу мөмкинлеге бирә. 3 июньнән товарларны экспортка озату белән бәйле чыгымнар республика бюджетыннан субсидияләнә. Бу "Халыкара кооперация һәм экспорт" гомумдәүләт проектын һәм "Башкортстан Республикасында экспортны үстерү" төбәк проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә мөмкин булды. Экспортерлар чыгымнарның 1 миллион сумга кадәрен кире кайтара ала, сынау партияләре буенча субсидия 500 мең сумга кадәр җитәчәк. Әлеге ярдәм чарасы Тышкы икътисади элемтәләр буенча дәүләт комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

# АЛИМЕНТ ТҮЛӘМӘСӘҢ, ИРЕГЕҢ БЕЛӘН ХУШЛАШАСЫҢ

Уфа шәһәренең Киров районы мировой суды 34 яшьлек ирне Җинаять кодексының 157 маддәсе буенча гаепле дип тапты. Судта ачыклануынча, бу бәндә, суд карары булуына карамастан, 2017 елдан алып кече яшьтәге кызына алимент түләмәгән. Шул рәвешле бурычы 406 мең сумга барып җиткән.

Судта ул үзенең гаебен тулысынча таныды һәм хәзер аңа 6 ай холык төзәтү эшләрендә катнашырга туры киләчәк.

# ХЕЗМӘТЛӘРЕ ӨЧЕН АКЧА СОРАГАН

Прокуратура "УИС" муниципаль унитар предприятиесенең элекке җитәкчесенә карата кузгатылган җинаять эшенә хөкем карары чыгарды.

Ул ришвәт алуда гаепләнә. Тикшерүчеләр фаразынча, быел мартта бер эшкуарның вәкиле гаепләнүче янына килә һәм торак булмаган бер бинага җылыту системасын кертүне үтенә. Бүлек начальнигы бу хезмәтләре өчен 60 мең сум акча сорый.

Әмма бу акча аны озак куандыра алмый: бераз вакыттан соң мут җитәкче Федераль иминлек хезмәткәрләре кулына эләгә...

**Илһам ХӘБИБУЛЛИН,**
**Уфа шәһәренең Киров районы прокуроры, юстициянең өлкән советнигы.**


## Информационное сообщение

Организатор торгов имущества ООО «ЭкоСистемз» – Назаренко Юрий Павлович (ИНН 027308320200, СНИЛС 078-895-763 59, nazarenko–ufa@yandex.ru, адрес для корреспонденции: 450057, Республика Башкортостан (далее РБ), г. Уфа, а/я 5025), член Ассоциации "НацАрбитр" (ИНН 7710480611, ОГРН 1137799006840, адрес: 101000, г. Москва, а/я 820), утвержденный решением Арбитражного суда города Москвы по делу №А40–85776/14 от 04.08.2016, сообщает о проведении повторных торгов посредством публичного предложения в сети Интернет на сайте электронной площадки ЗАО «Сбербанк – АСТ» – http://www.sberbank-ast.ru (далее – ЭП) по продаже имущества ООО «Экосистемз» (далее – продавец) (юр. адрес: 450077, РБ, г. Уфа, ул. Коммунистическая, д. 50, ИНН 0275029519, ОГРН 1020202771555). Имущество является предметом залога в пользу ООО «Центральный коммерческий банк». На торги выставляется Лот № 3: Автогазозаправочная станция (кадастровый номер 02:64:010604:22 инв. номер 80:415:002:000001330 общая площадь 1688,1 кв. м литера А, Б.В.I–IV, адрес объекта: РБ, Бирский р–н, г. Бирск, тер по ул. Кольцевой (АГЗ №31). Право аренды земельного участка из категории земель населенных пунктов, общей площадью 3398 кв.м., находящегося по адресу: РБ, г. Бирск, ул. Кольцевая, кадастровый номер: 02:64:01 06 04:0014. Н/ц 14763276 руб., м/ц 11662988,04 руб. Ознакомление участников с правоустанавливающими документами осуществляется по адресу: 450077, РБ, г. Уфа, ул. Коммунистическая, 50, по предварительной записи по тел.: 89875851006, с техническим состоянием имущества при осмотре. Величина снижения н/ц продажи имущества должника в форме публичного предложения определяется в размере 7% от н/ц лота. На первом периоде торгов, который составляет четырнадцать календарных дней, н/ц не меняется. При отсутствии в установленный срок заявки на участие в торгах на первом периоде, снижение н/ц продажи имущества, осуществляется последовательно каждые семь календарных дней. Задаток составляет 20% от н/ц продажи имущества каждого периода в ходе публичного предложения. Прием заявок с 11:00 02.07.2019 по 11:00 09.08.2019. Итоги торгов 12.08.2019 в 12–00 (время московское) на ЭП. Задаток должен поступить до окончания периода, в котором подана заявка на р/с продавца № 40702810406000020768 в Башкирском отделении №8598 ПАО Сбербанк г. Уфа, к/с 30101810300000000601, БИК 048073601. Прием заявок, проведение торгов и подведение итогов торгов проводится на сайте ЭП в соответствии с регламентом ЭП о проведении электронных торгов. Заявка на участие в торгах должна соответствовать положениям ст. 110, ст. 139 ФЗ «О несостоятельности (банкротстве) №127–ФЗ от 26.10.2002. Подробная информация об имуществе, ознакомление с условиями торгов, порядком оформления заявок, перечнем прикладываемых документов, проектами договоров и условиями их заключения, порядком оплаты, подведением итогов и другими сведениями размещена на сайте электронной площадки – ЗАО «Сбербанк – АСТ».


*Икътисади күзәтү*

# СӘНӘГАТЬНЕ ҮСТЕРҮНЕҢ ЯҢА БАСКЫЧЫ

## Тармак сәясәте үзәгендә — инвестицияләр җәлеп итү

**Бүгенге шартларда тотрыклылык һәм үсешнең нигезе — икътисадка инвестицияләр җәлеп итү. Билгеле булуынча, җитештерүне арттыруга юнәлеш тотып, средстволарны яңа предприятиеләр төзүгә яки булганнарын камилләштерүгә, заманча техника һәм технологияләрне үзләштерүгә салу (тотыну) инвестиция дип атала. Шулай ук мәгарифне үстерүгә, сәламәтлек саклауны камилләштерүгә тотынылган акчаларны да, "киләчәккә инвестицияләр" дип атыйлар. Инвестицияләр ул, гадиләштереп әйткәндә, эш урыннары, хезмәт хакы һәм салымнар, социаль-икътисади иминлек дигән сүз.**



Элена САЯПОВА коллажы.

Башкортстан Башлыгы вазыйфасын вакытлыча башкаручы Радий Хәбиров һәр атна саен Хөкүмәт әгъзалары һәм инвесторлар катнашлыгында республика икътисадына инвестицияләр җәлеп итүгә булышуга юнәлтелгән "Инвестиция сәгате" дигән утырыш үткәрә. Бу уңайдан республика җитәкчесе болай дигән иде: "Без мөмкинлекләрнең кайда һәм нинди позицияләр буенча тулысынча тормышка ашырылмавын ачык күрәбез. Республикада эшлекле мохитне тотрыкландыру буенча эш башладык. "Инвестиция сәгате"ндә проектлар буенча фикер алышабыз, аларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелегенә йогынты ясый торган мәсьәләләрне оператив хәл итәбез". Шулай ук "Инвестиция сәгате" муниципалитетларда да үткәрелә башлады. Кыскасы, Башкортстан Хөкүмәте барлык мөмкинлекләрне файдаланып, инвесторлар белән эшчәнлек алып бара (төбәкнең җәлеп итүчәнлеген күтәрү, законнарны икътисадка акча салучыларга уңайлырак итеп үзгәртү һ.б.). Ләкин әлегә, күләмнәрнең кимүеннән чыгып фикер йөрткәндә, хәл канәгатьләнерлек түгел.

– Әйтергә кирәк, әлеге вакытта ил буенча инвестиция активлыгы түбән. Өч ел дәвамында Русиядә инвестицияләр 7,9 процентка кимеде. Моның сәбәпләре төрле. Власть белән бизнес арасындагы бәйләнешләрнең начарлыгыннан алып, яңа куәтләрне сафка кертү юнәлешендәге эреле-ваклы киртәләргә кадәр.

Икътисадка инвестицияләр, яңача технологияләр, өстәмә эш урыннары, салым базасы киңәю, дидек. Шуңа күрә дә, төбәкләр арасында тышкы һәм эчке инвестицияләр өчен кискен көндәшлек көрәше бара. "Русия Федерациясенең күп кенә субъектларында, — диде Радий Хәбиров, инвестор офыкта күренү белән аны максималь хәстәрлеккә чорныйлар. Әзер җир участоклары турында мәгълүмат, "бердәм тәрәзә" тәкъдим итәләр, башка мәсьәләләрне хәл итәргә вәгъдә бирәләр. Бизнесны үстерү өчен иң яхшы шартларның нәкъ үзләрендә булуына, аннан да яхшыракны таба алмаячакларына ышандыралар. Әмма, ни аяныч, безнең республикада булачак инвесторның тәгаен кемгә мөрәҗәгать итәргә тиешлеген әлегә үзем дә ачыклый алмадым. Бизнес белән бәйләнешкә кергән таркау ведомстволар бик күп. Шул ук вакытта пешекчеләр күп булган җирдә ашның тәме булмавы мәгълүм. Эшлекле кешеләр республикага экскурсиягә килгән кебек килә һәм, акчасын салырга ашыкмыйча, кайтып китә. Болай эш бармый. Без дә инвесторларны күтәреп йөртәчәкбез".

*<u>Башкортстанның аерым төбәген генә түгел, ә гомум республиканы стратегик үстерүгә юнәлтелгән мөһим чара – "Инвестиция сабантуе" форумында да Радий Хәбиров инвестиция климатын яхшыртуның әһәмиятен янә ассызыклады.</u>*

Башкортстанның аерым төбәген генә түгел, ә гомум республиканы стратегик үстерүгә юнәлтелгән мөһим чара – "Инвестиция сабантуе"форумында да Радий Хәбиров инвестиция климатын яхшыртуның әһәмиятен янә ассызыклады. "Инвестиция сәгате"нең Хөкүмәттә һәм муниципалитетларда үткәрелүен, шәһәр-районнарда малтабарлык өчен җаваплы вазыйфа булдырылуын, контроль-күзәтчелек органнары белән аңлашып эшләүне билгеләде ул. Республика башлыгы малтабарлыкка ярдәм итә торган инфраструктура төзелүне (алгарышлы үсеш территорияләре һ.б.) атады.

Стратегик башлангычлар агентлыгының генеральный директоры (АСИ) Светлана Чупшева әлеге форумдагы чыгышында инвестиция климаты буенча гомумдәүләт рейтингында Башкортстанның уналтынчы урындалыгын әйтеп үтте. Бу күрсәткеч буенча Башкортстан бер ел эчендә җиде баскычка күтәрелгән.

АСИ җитәкчесе шулай ук төбәк властьларының бизнеска уңай мөнәсәбәтен билгеләде. Малтабарлык тармагына ярдәм итүгә юнәлтелгән инструментлар яңача эшли башлады, диде ул.

Әйе, бүгенге Башкортстан – Русиянең тотрыклы икътисадлы һәм бюджетлы, ныклы, уңышлы субъекты. Башкортстан икътисадына инвестицияләр җәлеп итү белән бәйле чаралар республикада гына түгел, ә илнең төрле төбәкләрендә, төрле дәрәҗәдәге форумнарда да үтә. Алар нәтиҗә бирми калмаячак, әлбәттә.

Шулай ук Русия Президенты Владимир Путинның "2024 елга кадәр Русия Федерациясен үстерүнең гомумдәүләт максатлары һәм стратегик бурычлары турында"гы Указына ярашлы кабул ителгән гомумдәүләт проектларын тормышка ашыру Башкортстанны социаль-икътисади үстерүнең яңа баскычы дип билгеләнде.

**Идрис СӘЕТГАЛИЕВ.**


Издательство "Кызыл таң" — филиал ГУП РБ Издательский дом "Республика Башкортостан". Учредители республиканской общественно-политической газеты "Кызыл таң" — Государственное собрание — Курултай, Правительство Республики Башкортостан. Издается с 1 марта 1918 года. Выходит во вторник, четверг и пятницу на татарском языке.

**Баш мөхәррир**
**Фаил Камил улы ФӘТХЕТДИНОВ.**
**Мөхәрририят:**
**Илдар Фазлетдинов** (җаваплы секретарь), **Фәнис Гәрәев, Резеда Нуртдинова, Рәфис Сәяхов**, **Олег Төхвәтуллин** (баш мөхәррир урынбасарлары), **Фәрит Фаткуллин.**

Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы: 450079, БР, Уфа, Октябрьнең 50 еллыгы урамы, 13, 6нчы кат.
Адрес редакции и издателя: 450079, РБ, Уфа, ул. 50-летия Октября, 13, 6-й этаж.
kyzyltan@mail.ru

Гәзит Элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәттә 2008 елның 24 сентябрендә теркәлде.
Теркәлү саны — ПИ №ФС 77-33268
Күләме – 4 басма табак
Гомум тиражы —5337 данә
<u>Заказ № 1030.</u>

Гәзит "Кызыл таң" нәшриятының компьютер цехында җыелды һәм Нефтекама матбугат йорты типографиясендә басылды: 452680, БР, Нефтекама шәһәре, Березовка шоссесы, 4А, тел. (8-34783) 7-07-57.
Газета отпечатана в типографии Нефтекамского дома печати. 452680, РБ, г. Нефтекамск, Березовское шоссе, 4А, тел. (8-34783) 7-07-57.

**Телефоннар:**

| | |
|---|---|
| Кабул итү бүлмәсе — | 272-13-61 |
| баш мөхәррир урынбасарлары — | 272-97-71; 273-50-56 |
| җаваплы секретарь — | 272-74-05 |
| Бүлекләр: | |
| сәясәт, икътисад һәм милли проблемалар — | 272-58-40 |
| әдәбият һәм сәнгать — | 272-35-22 |
| авыл тормышы һәм үз хәбәрчеләр челтәре — | 273-46-19 |
| яңалыклар — | 272-75-68 |
| хатлар һәм социаль мәсьәләләр — | 272-82-07 |
| рәссам — | 272-75-21 |
| реклама — | 272-62-27 |
| маркетинг — | 272-35-70 |
| бухгалтерия — | 273-43-43 |
| тәрҗемәчеләр — | 272-74-52 |
| "Әллүки" журналы — | 272-62-19 |
| "Тулпар" журналы — | 272-67-48 |

Факс — 273-88-01, 272-62-27

**Үз хәбәрчеләребез:**

| | |
|---|---|
| Октябрьский, Бүздәк, Әлшәй, Благовар | 8-937-30-24-087 |
| Борай, Кушнаренко, Дүртөйле | 8-917-80-37-750 |
| Илеш, Бакалы, Шаран | 8-937-49-35-735 |

*Гәзит чыгышларына карата килгән хатларга җавап бирелми, кулъязмалар, фотолар, рәсемнәр рецензияләнми, кире кайтарылмый. Редакциянең консультация бүлеге юк. Авторлар фикеренең редакциянеке белән туры килүе зарури түгел.*

*Реклама һәм игъланнарның эчтәлеге өчен реклама бирүчеләр җаваплы.*

"Кызыл таң"ның индексы:
атнага өч тапкыр басылганыныкы — П2760
атнага бер тапкыр — П3408
"Әллүки" журналы — П2712
"Тулпар" журналы — П2715

Безнең дәүләт банкы реквизитлары:
Издательство "Кызыл тан" филиал ГУП РБ Издательский дом "Республика Башкортостан"
БАШКИРСКИЙ РФ АО "РОССЕЛЬХОЗБАНК"
р/с 40602810862000000102
к/с 30101810200000000934
БИК 048073934
ИНН 0278066967
КПП 027843006
ОКПО 31226910
ОКВЭД — 58.13.1
Дежур: Д. СӨЛӘЙМАНОВА, Ю. ТӨХБӘТУЛЛИНА.


© "Кызыл таң" № 74 (25378). 12+

# "ПАРТИЯЛӘР ЙОКЫДАН УЯНЫРГА ТИЕШ"

**Дәүләт җыелышы-Корылтай йортында республика парламенты Рәисе Константин Толкачев сәяси партияләрнең төбәк бүлекчәләре җитәкчеләре белән очрашты. Чарада Үзәк сайлау комиссиясе рәисе Илона Макаренко, Башкортстанның Сәяси пар-тияләренең төбәк бүлекчәләре партияара советы рәисе Валерий Аббасов, республика Башлыгы Хакимияте, Хөкүмәт вәкилләре, Дәүләт җыелышы-Корылтай депутатлары, сәяси партияләрнең 20дән артык төбәк бүлекчәсе җитәкчеләре катнашты.**

Константин Толкачев, очрашуда катнашучыларны сәламләп, бүген Русиядә 61 сәяси партия теркәлүен, 47 партиянең Башкортстанда төбәк бүлекчәләре барлыгын билгеләде.

– Кызганычка каршы, партияләр саны күп булуга карамастан, аларның кайберләре формаль рәвештә генә гамәлдә. Бу бер көнлек партияләр, аларның бүлекчәләрендә берничә әгъза гына эшли һәм алар партия эшен алып бармый диярлек, – диде Константин Толкачев. – Без эшләргә теләүче партияләрне реабилитацияләү бурычын куябыз. Алар йокыдан уянырга, республиканың сәяси һәм иҗтимагый тормышында актив катнашырга тиеш. Алар үзләре дә моның белән кызыксыныр дип ышанам, чөнки һәр партия үзенең электоратының, аерым төркем гражданнарның мәнфәгатьләрен һәм сәяси ихтыярын чагылдыра. Барлык сәяси партияләрнең дә төп максаты бер – кешеләрнең тормыш дәрәҗәсен күтәрү.

Константин Толкачев ассызыклавынча, алтынчы чакырылыш республика парламенты элеккесе белән чагыштырганда, күппартиялелек шартларында эшли. Анда "Бердәм Русия", КПРФ, ЛДПР, "Гадел Русия" партияләренең үз фракцияләре бар, моннан тыш, Дәүләт җыелышы-Корылтайда "Русия патриотлары" һәм "Яшелләр" Русия экология партиясе" вәкилләре дә бар. Сайлаулар нәтиҗәләре буенча парламент составына кермәгән партияләр Дәүләт җыелышы-Корылтайның барлык эксперт советларында да тәкъдим ителгән.

Очрашу барышында, шулай ук, республика һәм федераль законнарны камилләштерү, бу процесска парламентка кермәгән партияләрне җәлеп итү турында фикер алыштылар. Константин Толкачев республика парламенты эшчәнлеге, Дәүләт җыелышы-Корылтайның законнар чыгару башлангычларын федераль дәрәҗәдә алга этәрү, башка төбәкләр һәм илләр парламентлары белән хезмәттәшлек итү турында сөйләде. Фикер алышулар булды, партияләрнең төбәк бүлекчәләре җитәкчеләре җир-милек мөнәсәбәтләре, торак-коммуналь хуҗалык, күпбалалы гаиләләргә ярдәм, хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге законнарны үстерү буенча тәкъдимнәре белән уртаклашты. Кабул ителгән тәкъдимнәр республика парламенты комитетларына тапшырылды.

# УНИВЕРСИТЕТ РЕКТОРЫ САЙЛАНДЫ

**М. Акмулла исемендәге Башкортстан дәүләт педагогия университетының фәнни-педагогик хезмәткәрләре һәм укучылары конференциясе узды, анда күпчелек тавыш белән киләсе биш елга вуз ректоры итеп Салават Сәгыйтовны сайлау турында карар кабул ителде.**

Ректор вазыйфасына өч кандидат дәгъва иткән. Алар – фәнни һәм инновацион эшчәнлек буенча проректор Илья Кудинов, Тарих һәм хокукый белем бирү институты директоры Алексей Кортунов һәм ректор вазыйфасын вакытлыча башкаручы Салават Сәгыйтов. Һәр кандидат вузны үстерү буенча үз программасын тәкъдим итте.

– Планнарыбыз күп. Стратегик максат – илнең педагогик югары уку йортлары, Урал-Идел буе төбәге вузлары арасында академик, технологик, эшкуарлык компетенцияләре белгечләрен әзерләү буенча тотрыклы лидер булу, – диде Салават Сәгыйтов. – Без белем бирү, фәнни һәм социаль эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген арттырырга, вузны Башкортстанның тотрыклы социаль үсеше, традицияләрне саклап калу һәм инновацион педагогик технологияләр кертү өчен ресурслар һәм проектлар берләштерүче фәнни-мәгариф һәм социаль-мәдәни үзәк буларак үстерүгә игътибар бүләргә тиеш.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча 105 сайлаучы үз тавышларын Салават Сәгыйтовка бирде. Ул күрсәткән ышаныч өчен коллективка рәхмәт белдерде.

**Үз хәбәрчебез.**

*Сорау-җавап*

# Кандидатлар фильтр аша үтә

**Тәкъдим ителгәннән соң, кандидатларга үз кандидатураларын яклау өчен муниципаль берәмлекләрнең вәкаләтле органнары депутатларының 454 имзасын җыярга кирәк. Бу – муниципаль берәмлекләр уставларында республика Башлыгын сайлауны тәгаенләү турында карар кабул ителгән көнгә күрсәтелгән депутатларның гомум саныннан 5 процент. Депутатлар имзалары арасында муниципаль районнар һәм шәһәр округларының 48дән дә ким булмаган вәкаләтле органының 56 депутатының култамгасы булырга тиеш. Шушы уңайдан Башкортстан Үзәк сайлау комиссиясе рәисе урынбасары Марат Гадилов аңлатма бирде.**

– Кандидатны яклау муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы депутаты тарафыннан кандидатны хуплау кәгазендә, дата һәм сәгатен күрсәтеп (арытаба – хуплау кәгазе), имза кую белән гамәлгә ашырыла, – диде Марат Венер улы. – Имзаның чын булуын нотариус расларга тиеш.

Муниципаль берәмлекнең вәкаләтле органы депутаты теләсә кайсы сәяси партия күрсәткән бер кандидатны гына яклый ала. Имзаларны тикшергәндә урындагы үзидарә органы депутаты берничә кандидатны яклавы ачыкланса, вакыты буенча алдарак куелган имза дөрес дип исәпләнә. Имзаны кире кайтарып алу рөхсәт ителми.

Имзаларны җыю барышында муниципаль берәмлекләрнең вәкаләтле органнары депутатларын култамга куярга мәҗбүриләү һәм моның өчен аларны бүләкләү тыела.

Хуплау кәгазьләренә куелган имзаларның дөреслеге депутатларның имзалары булган хуплау кәгазьләрен теркәү өчен Башкортстан Республикасы Башлыгы вазыйфасына кандидатлар тарафыннан тапшырылган документларны кабул итү һәм тикшерү буенча Башкортстан Үзәк сайлау комиссиясе әгъзаларыннан төзелгән Эшче төркем тарафыннан тикшерелә.

Имзаланган кәгазьләрне кандидатны теркәү өчен кирәкле башка документлар белән бергә Башкортстан Үзәк сайлау комиссиясенә агымдагы елның 1 июленнән дә иртәрәк түгел һәм 11 июленнән дә соңга калмыйча урындагы вакыт белән 18.00 сәгатькә кадәр тапшыру зарур.

Башкортстан Үзәк сайлау комиссиясе документларны, шул исәптән кандидатны хуплау кәгазендә куелган имзаларның дөреслеген, 10 көн эчендә, әмма 2019 елның 20 июленнән дә соңга калмыйча тикшерергә тиеш.

Башкортстан Үзәк сайлау комиссиясе кандидатны хуплау кәгазенә үз имзаларын куйган кешеләрнең исемлеген төбәк дәүләт матбугат басмасында яисә Башкортстан Үзәк сайлау комиссиясе сайтында күрсәтелгән исемлекне тәкъдим иткән көннән алып өч көн эчендә, әмма агымдагы елның 13 июленнән дә соңга калмыйча урнаштыра.